**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об установлении ограничительных мероприятий (карантина) на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию высокопатогенным гриппом птиц и угрозой его распространения

В связи с выявлением заболевания высокопатогенным гриппом птиц и угрозой его распространения, в соответствии со статьями $3^1$, 17 Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии», приказом Министерства сельского хозяйства Российской Федерации от 24 марта 2021 года № 158 «Об утверждении Ветеринарных правил осуществления профилактических, диагностических, ограничительных и иных мероприятий, установления и отмены карантина и иных ограничений, направленных на предотвращение распространения и ликвидацию очагов высокопатогенного гриппа птиц» **постановляю**:

1. Установить ограничительные мероприятия (карантин) по высокопатогенному гриппу птиц на территориях эпизоотического очага, угрожаемой зоны и зоны наблюдения, определенных пунктом 2 настоящего Указа, на период до их отмены.

2. Определить:

а) эпизоотический очаг в пределах территории, занимаемой помещениями, используемыми крестьянским (фермерским) хозяйством «Фролов Эдуард Александрович» и расположенными в селе Калмаш Тукаевского района Республики Татарстан;

б) угрожаемую зону в пределах территории радиусом 5 км от границ эпизоотического очага, включая село Калмаш, поселок Новый, село Верхний Байлар Тукаевского района Республики Татарстан;

в) зону наблюдения в пределах территории, прилегающей к угрожаемой зоне, радиус которой составляет не менее 10 км от ее границ, включая деревню Игенче, деревню Новый Байлар, село Кузкеево, поселок Сосновый Бор, село Шильнебаш, поселок совхоза «Татарстан», село Семекеево, деревню Кугашево, деревню Чершелы, деревню Старый Байлар, деревню Тавларово, деревню Малтабарово, село Калмия, деревню Биюрган, деревню Кулушево, деревню Кырныш, село Ильбухтино, деревню Малая Шильна, село Большая Шильна, деревню Азьмушкино, село Старые Гардали,

деревню Новые Сарайлы Тукаевского района Республики Татарстан, село Подгорный Такермен, село Верхний Такермен, село Кузембетьево, деревню Усаево, поселок Новая Александровка, деревню Бакчасарай, село Тулубаево, деревню Урусово Мензелинского района Республики Татарстан, город Набережные Челны.

3. Запретить:

а) в эпизоотическом очаге:

лечение больных птиц;

посещение территории посторонними лицами, кроме персонала, выполняющего производственные (технологические) операции, в том числе по обслуживанию птиц, специалистов госветслужбы и персонала, привлеченного для ликвидации очага, лиц, проживающих и (или) временно пребывающих на территории, признанной эпизоотическим очагом;

ввоз и вывоз птиц, инкубационного яйца;

перемещение и перегруппировку птиц;

убой птиц с целью получения продуктов убоя;

вывоз продуктов убоя птиц и иной продукции птицеводства;

вывоз кормов для всех видов животных, с которыми могли иметь контакт больные птицы;

снятие пера и пуха с павших птиц;

вывоз инвентаря и иных материально-технических средств, с которыми могли иметь контакт больные птицы;

выгульное содержание птиц;

закладку яиц на инкубацию;

въезд и выезд транспортных средств (за исключением транспортных средств, задействованных в мероприятиях по ликвидации эпизоотического очага и (или) обеспечении деятельности лиц, проживающих и (или) временно пребывающих на территории хозяйства);

б) в угрожаемой зоне:

ввоз и вывоз птиц и инкубационного яйца;

заготовку и вывоз кормов для птиц;

выгульное содержание птиц;

проведение сельскохозяйственных ярмарок, выставок, торгов и других мероприятий, связанных с передвижением, перемещением и скоплением птиц и животных других видов;

охоту на птиц, отнесенных к охотничьим ресурсам, за исключением охоты в целях регулирования численности охотничьих ресурсов.

4. Главному управлению ветеринарии Кабинета Министров Республики Татарстан разработать и утвердить план мероприятий по ликвидации очага высокопатогенного гриппа птиц и предотвращению его распространения на территории Республики Татарстан, включая мероприятия, обязательные к проведению на территории зоны наблюдения.

5. Контроль за исполнением настоящего Указа возложить на Кабинет Министров Республики Татарстан.

6. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
23 ноября 2021 года
№ УП-894

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы һәм аның таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, аларның имин булмавы сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында**

Йогышлылыгы югары булган кош гриппы очрагы ачыклану һәм аның таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^{1}$, 17 статьялары, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Йогышлылыгы югары булган кош гриппы таралуын һәм аның чыганакларын бетерүгә юнәлтелгән карантин һәм башка чикләүләр кертү һәм аларны бетерү буенча профилактика, диагностика, чикләү һәм башка чараларны тормышка ашыру буенча ветеринария кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 24 мартындагы 158 номерлы боерыгы нигезендә **карар бирәм:**

1. Йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән бәйле рәвештә, аны бетерү турында карар кабул ителгәнгә кадәр, әлеге Указның 2 пункты нигезендә билгеләнгән эпизоотия чыганагы һәм имин булмаган пункт территорияләрендә чикләү чаралары (карантин) кертергә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) Татарстан Республикасы Тукай районы Калмаш авылында урнашкан һәм «Фролов Эдуард Александрович» крестьян (фермер) хуҗалыгына кергән биналар территориясендә эпизоотия чыганагын;

б) эпизоотия чыганагыннан 5 км радиустагы территория чикләрендә, Татарстан Республикасы Тукай районының Калмаш авылын, Яңа поселокны, Югары Байлар авылын кертеп, куркыныч янау зонасын;

в) куркыныч янау зонасын чикләреннән 10 км радиустагы территория чикләрендә, Татарстан Республикасы Тукай районының Игенче авылын, Яңа Байлар авылын, Күзкәй авылын, Сосновый Бор поселогын, Шилнәбаш авылын, «Татарстан» совхозы поселогын, Сәмәкәй авылын, Күгәш авылын, Чыршылы авылын, Иске Байлар авылын, Таулар авылын, Малтабар авылын, Калмия авылын, Боерган авылын, Колыш авылын, Ильбухтино авылын, Кече Шилнә авылын, Олы Шилнә авылын, Әҗмәкәй авылын, Иске Гәрдәле авылын, Яңа Сарайлы авылын, Татарстан Республикасы Минзәлә районының

Тауасты Тәкермән авылын, Югары Тәкермән авылын, Хуҗамәт авылын, Усай авылын, Яңа Александровка поселогын, Бакчасарай авылын, Тулыбай авылын, Ырыс авылын, Чаллы шәһәрен кертеп, күзәтү зонасын.

3. Түбәндәгеләрне тыярга:

а) эпизоотия чыганагында:

чир йоктырган кошларны дәвалауны;

производство (технологик) операцияләрне башкаручы персоналдан, шул исәптән кошларны караучылар, дәүләт ветеринария белгечләре һәм чыганакны бетерү өчен җәлеп ителгән персоналдан, эпизоотия чыганагы дип танылган территориядә яшәүче яисә вакытлыча килгән затлардан тыш, чит кешеләрнең территориягә керүен;

яралгылы йомыркаларны территориягә алып керүне һәм чыгаруны;

кошларны күчерүне һәм төркемнәргә яңадан бүлүне;

продукт алу максатында кошларны чалуны;

чалынган кошларны һәм кошчылыктан алынган башка продукцияне территориядән читкә чыгаруны;

чир йоктырган кошлар янәшәсендә булган азыкны терлекләрнең барлык төрләре өчен территориядән чыгаруны;

кош үләксәсенең йонын һәм мамыгын йолкуны;

чир йоктырган кошлар янәшәсендә булган эш кораллары һәм башка матди-техник чараларны территориядән чыгаруны;

кошларны иректә асрауны;

йомыркаларны яралгыга салуны;

транспорт чараларының территориягә керүен һәм чыгуын (эпизоотия чыганагын бетерү һәм (яисә) хуҗалык территориясендә яшәүче яисә вакытлыча килгән затларның эшчәнлеген тәэмин итү чараларында катнашучы транспорт чараларыннан тыш);

б) куркыныч янау зонасында:

кошларны һәм яралгылы йомыркаларны территориягә алып керү һәм чыгаруны;

кошларга азык әзерләү һәм территориядән чыгаруны;

кошларны иректә асрауны;

авыл хуҗалыгы ярминкәләре, күргәзмәләре, сәүдә һәм кошларның, терлекләрнең башка төрләрен транспортта йөртү, күчерү һәм туплау белән бәйле башка чараларны уздыруны;

аучылык ресурсларын санын тиешле дәрәҗәдә тоту максатында аулаудан тыш, аучылык ресурслары булып торган кошларны аулауны.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йогышлылыгы югары булган кош гриппы вирусы чыганагын бетерү һәм авыру чыганагының Татарстан Республикасы территориясендә таралуын булдырмау буенча, күзәтү зонасы

территориясендә уздырылырга тиешле чараларны да кертеп, чаралар планын эшләргә һәм расларга.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 23 ноябрь
№ ПУ-894